**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт идарәсен оештыру һәм координацияләү чаралары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт идарәсен оештыру һәм координацияләү чаралары турында» 2007 елның 8 сентябрендәге ПУ-511 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-204 номерлы, 2009 елның 5 сентябрендәге ПУ-482 номерлы, 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-235 номерлы, 2012 елның 11 июлендәге ПУ-457 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2013 елның 6 августындагы ПУ-716 номерлы, 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 22 февралендәге ПУ-198 номерлы, 2015 елның 19 мартындагы ПУ-298 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1094 номерлы, 2016 елның 3 февралендәге ПУ-76 номерлы, 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1092 номерлы, 2017 елның 16 июнендәге ПУ-507 номерлы, 2018 елның 19 апрелендәге ПУ-325 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2019 елның 11 апрелендәге ПУ-216 номерлы, 2019 елның 10 сентябрендәге ПУ-531 номерлы, 2020 елның 10 февралендәге ПУ-73 номерлы, 2021 елның 26 августындагы ПУ-675 номерлы һәм 2021 елның 12 ноябрендәге ПУ-871 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбулада «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең законнар чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 18 статьясы» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан Л.Р. Габдерахмановны, Ф.С. Ильинны, А.Ә. Кәримовны, М.Н. Садыйковны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Гарипов Рөстәм Рамил улын – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Коробченко Олег Владимировичны – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрын;

Миңнуллин Марсель Мансур улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.Н. Миңнехановның – «Татарстан Республикасы Рәисе, Комиссия рәисе»;

И.М. Гариповның – «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2023 ел, 10 май
№ 286